**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Сухояшского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

С.Большой Сухояш, ул.Школьная 4-2,
Азнакаевского муниципального района,
423325 Тел. (факс) (85592) 34-6-16
Suho.Azn @tatar.ru

Зур Сукаеш авылы, Мәктәп урамы,4-2,
Азнакай муниципаль районы, 423325
Тел.(факс)(85592) 34-6-16
Suho.Azn @tatar.ru

---

04.02.2021г. № 5

**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитетының 14.04.2018 елның 5 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында (18.07.2018 № 11 карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитетының 14.04.2018 елның 5 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә (18.07.2018 № 11 карар редакциясендә), 24 нче пунктны түбәндәге эчтәлелекле 7 нче пунктча белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http//pravo.tatarstan.ru. веб – адресы буенча урнаштыру юлы белән һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Закирова З.Җ.